

**Хәйдарова (Солтанова) Вәсилә Нургали кызы**

1939 нчы елның 14 нче апрелендә, Мөслим районы Яңа Сәет авылында туган.

1946 нчы елда Яңа Сәет башлангыч мәктәбенә, 1950 нче елда Мари - Бүләр җидееллык мәктәбенә укырга кереп, 1954 нче елда мәктәптә укуын тәмамлый. Шушы ук елны Минзәлә педагогия училищесына укырга керә һәм 1958 нче елда училищены кызыл дипломга тәмамлый.

1958 нче елның сентябреннән 1961 нче елның сентябренә кадәр Минзәлә районында эшли. 1960 нчы елда Казан Дәүләт университетына укырга керә һәм 1966 нчы елда кулына диплом ала.

1961 нче елда Әмәкәй сигезъеллык мәктәбендә рус теле һәм әдәбияты, 1962 нче елда Симәк сигезъеллык мәктәбендә рус теле һәм немец теле, 1969 нчы елда Яңа Усы мәктәбендә немец теле, 1970 нче елда Ташлыяр сигезъеллык мәктәбендә рус теле һәм әдәбияты дәресләрен укыта.

1971 нче елдан башлап Салавыз - Мухан мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укыта. Бу мәктәптә эшләгән чорында Вәсилә Нургали кызы үзен яхшы фәнни - теоретик һәм методик әзерлекле булуын күрсәтә. Бик күп еллар агитатор вазыйфасын үти, мәктәптә “ Яшь бөреләр” түгәрәге җитәкчесе була. Түгәрәк әгъзаларының иҗади эшләре матбугат битләрендә басыла. Вәсилә Нургалиевна үзе дә шигырьләр яза, кичәләр һәм бәйрәмнәр өчен эшкәртмәләре Мәгариф журналы битләрендә урын ала. Лаеклы ялга чыккач та Вәсилә Нургали кызы шәхси китапларын бастырып, иҗат юлын дәвам итә.



Мәктәпнең укытучылар методик берләшмәсен җитәкли. 1988 нче елда аның педагогик эш тәҗрибәсе турындагы альбом республиканың ВДНХ күргәзмәсенә җибәрелде. Вәсилә Хәйдарова көчле оештыру сәләтенә ия, шуның нәтиҗәсе, укучылар һәм укытучыларны туплап куелган концерт һәм спектакльләрне авыл халкы, күрше - тирә авыл тамашачысы бик җылы кабул итә. 1990 нчы елда бу ханымга “Халык мәгарифе отличнигы”, 1991 нче елда “Укытучы - методист” 1992 нче елда “Әйдәп баручы укытучы” исемнәре бирелә. 1995 нче елдан башлап, Сарман районы мәгариф бүлегендә методист булып эшли. Аның мәгариф системасында эшләү чоры – 40 ел.

Вәсилә Хәйдpraвоның сөйләгәннәреннән: “Яңадан 40 ел эшләр идем, тормыш үзенекен итә шул, яшь бара. Мәктәп тормышыннан , балалардан мин беркайчан да туймаячакмын, алдагы тормышым алардан башка төпсез

караңгылыкка күмелер төсле.

Ходай миңа бик яхшы хәтер биргән, хәзер дә бик күп догаларны, коръән сүрәләрен яттан өйрәнә алам. Әле күптән түгел генә Чаллы мәчете каршында оештырылган курсларны тәмамлап, кулыма шәһадәтнамә алдым”.

Шигъри истәлекләре:

Укытучыма

Һаваларда якты йолдыз яна,
Тирә якка сибә якты нур.
Кап караңгы көннәрдә дә балкый-
Син кабызган якты йолдыз ул.

Алдыбызда иркен, озын юллар-
Күзен кыса кояш нурлары.
Бу -киләчәк тормышка илтәчәк,
Укытучымның сызган юллары.

Иңнәремдә - йомшак җылы кулың,
Колагымда - әйткән сүзләрең.
Безгә төбәп сынау белән карый,
Шатлык тулы коңгырт күзләрең.

Мул табынлы, икмәкле, тозлы бул.
Тәмле булсын эчкән суларың.
Сине уйлап янәшәңнән атлый
Белем биргән ул һәм кызларың.

**Биккинина Рәйсә Идрис кызы истәлекләреннән:**



“Сугыштан соңгы авыр еллар. Укырга кергәндә киярлгә форма да юк иде. Чуар күлмәкләрдән, аякка ни табалар шуны киеп бардык. Сукыр лампа яктысында дәрес әзерләдек, берничә елдан соң кичке 10 - 11ләргә кадәр яна торган ут керттеләр. Бик яшьли колхоз эшенә йори башладык, басудан ипи ташыдык ындыр табагында һ. б. җирләрдә эшләдек. 4 нче класста укыганда үк әткәй чалгы тотарга өйрәтте”, –дип искә алды Рәйсә апабыз.

Рәйсә апа үзенең тормышындагы кызыклы вакыйгасын да искә төшереп китте: ”10 нчы класста укыганда татар җыр сәнгатендә иң күренекле, иң атаклы, үз җырлау манерасы, үз мәктәбе, үз юлы булган җырчы Илһам Шакиров концерт белән килде, басуларны карарга менгән иде. ”Шулай авыр эшләрдә эшлисең мени”,- дип чалгыны алып, ул да чабып карады”.

1970 нче елда Алабуга Дәүләт педагогия институтын тәмамлагач Кирамова Рәйсә Идрис кызы Күбәк урта мәктәбендә үзенең хезмәт юлын башлый. Ике ел эшләгәннән соң, ягъни 1972 нче елда, Салавыз - Мухан

мәктәбендә эшли башлый, яшь кызга завуч һәм рус теле, әдәбияты укытучысы эшен йөклиләр.



Биккинина Рәйсә Идрис кызы пенсиягә чыкканчы, 2001 нче елга кадәр, шушы мәктәптә балалар укыта. Аның хезмәте район мәгариф бүлеге һәм республика, РСФСР мәгариф министрлыгының мактау кәгазьләре белән бәяләнә. Хезмәт ветераны исеменә лаек була.

Рәйсә апаның укыту дәверендә биш чыгарылышы була. Аның укучылары төрле җирләрдә хезмәт куялар: табиб та, игенче, терлекче, укытучы, эшче һ.б. һөнәр ияләре күп.

Алар үзләренең укытучыларын онытмыйлар, хәлләрен белешеп торалар.

Рәйсә Идрис кызы хезмәттә генә түгел, гаиләдә дә уңган хуҗабикә, яраткан әни. Туганнары арасында кадерле апа. Яшь укытучыларның остазы, укучыларның яраткан мөгаллиме.



**Мәрдәнова Бәһия Әхәт кызы** 1947 нче елның 1 декабрендә дөньяга килә. Балачагы Мөслим авылында үтә. 1955 нче елны 1 нче класска укырга керә. Мөслим урта мәктәбендә сигезенче классны тәмамлагач, шәфкать туташы булу теләге белән, Минзәлә медицина училищесына укырга керә. 1967 нче елда аны уңышлы тәмамлап, Салавыз – Мухан авылында шәфкать туташы булып эшли башлый. Алган белемнәрен тирәнәйтү максатында Бәһия Әхәтовна Казан шәһәренә юнәлә. Ул вакытта да медицина институтына конкурс бик зур була, шунлыктан ул 1972 нче елда Казан Дәүләт педагогия институтының химия – биология факультетына укырга керә. 1977 нче елда институтны бетереп, укытучы буларак, хезмәт юлын Метрәй урта мәктәбендә башлый.


1978 нче елдан Мәрдәнова Бәһия Әхәтовна Салавыз - Мухан мәктәбендә химия - биология фәннәрен укытуга күчә. Химия – биология укытучысы буларак, ул үзен табигать кешесе, чәчәкләр, үсемлекләр дөньясында дип хис иткән. Үз фәнен бик яраткан, дәресләрен кызыклы һәм мавыктыргыч итеп, укучыларның актив катнашында үткәргән. Шул рәвешле эшләп, ул балаларда әлеге фәнгә карата тирән мәхәббәт тәрбияләгән. Нәтиҗәдә, аның укучылары химия - биология олимпиадаларында район күләмендә



призлы урыннарга чыкканнар. Югары уку йортларына кергәндә әлеге фәннәрдән имтиханнарны яхшы билгеләренә тапшырганнар. Бәһия Әхәтовна мәктәптә эшләгән чорында ике тапкыр Россия министырлыгының һәм республика, район мәгариф бүлекләренең мактау кәгазьләре белән бүләкләнгән.

Бәһия апа, гаиләсендә уңган хуҗабикә, үрнәк әни. Хаҗиәхмәт абый белән матур гомер итеп бер ул, бер кыз үстерделәр.

“Эшемне бик яратып эшләдем, табигатьне һәм балаларны бик якын күрәм, ишек алдында да кырыктан артык бакча гөле үстерәм”–дип сөйләде безгә Бәһия апа.



**Ханнанов Миргарифан Мирзагали улы** 1954 нче елның 7 нче февралендә Мөслим районы Яңа Сәфәр авылында туып үскән. Биш яшеннән гармунда уйнарга өйрәнә. Гармунынннан чак кына зуррак малайны бер генә каз өмәсеннән дә калдырмыйлар. Дәүҗия апасының өйдә шыңшып йөрүеннән башка җыр ишеткәне юк әле малайның. Миргалим абыйсы гармун алып биргәч, апасы артыннан калмый. “Апа, бер җыр өйрәт әле”,- дип теңкәсенә тия. “Фәлән эшне эшләсәң, өйрәтәм”,- дип Дәүҗия аның үтенечен шаян сүз белән уздырып котылмакчы була. Әмма төпчек төпчеклеген итә, апасының йомышларын үти дә, тагын бәйләнә. Шулай итеп, нәни Миргарифанның күңеленә беренче җыр, беренче моң уела. 1961 - 1964 нче елларда Яңа Сәфәр башлангыч мәктәбендә укый. 1964 - 1969 нчы елда Башкортстанның Бакалы районы Казанчы мәктәбен тәмамлагач, Әлмәт физкультура техникумына укырга керә. Әмма баянынннан бервакытта да аерылмый. Сәхнә аның гомерлек юлдашына әверелә. Техникумны тәмамлаганнан соң, аны Актаныш районы Чуракай мәктәбенә физкультура укытучысы итеп җибәрәләр. Анда да агтибригада чыгышларында катнашып, танылган баянчыга әверелә. Аннары - армия. Биредә аны рота комсоргы итеп билгелиләр. Комсомол эше аның киләчәк карьерасын да билгеләп куя.



Армиядан соң, туган якка кайтып, Баек мәктәбендә беркадәр укыткач, Саратов югары партия мәктәбен тәмамлый. 1985 - 1995 нче елларда Салавыз - Муханда партком секретаре, совхоз директоры булып эшли. 1995 -

2003 нче елларда Салавыз - Мухан мәктәбендә тарих, география фәннәрен укыта. 2003 - 2005 нче елларда Мөслим районы культура бүлеге җитәкчесе булып эшли. 2005 - 2014 нче елларда Салавыз - Мухан мәктәбендә директор булып хезмәт куя. Кайда гына эшләмәсен, тормышын сәхнәдән башка күз алдына да китерми. Миргарифан Ханнановның иң зур горурлыгы, мөгаен, авыл үзешчәннәре белән куйган спектакльләрдер. “Зәңгәр шәл”, “Язылмаган законнар”, “Әни килде”, “Гайфи бабай, өйлән давай”... Һәркайсында да Миргарифан - төп рольдә.  Болардагы персонажларны уйнау өчен ярты Мухан халкын тартырга Миргарифан Ханнановның оештыру сәләте дә ярдәм иткәндер.

Икенче горурлыгы - талантлары ачылган балалар. Мухан мәктәбенең генә түгел, районның күп кенә балаларына икенче сулыш бирде ул. Шуның нәтиҗәсе буларак, 2008 нче елда аңа мәдәният өлкәсендәге яхшы  хезмәте өчен “Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре” дигән мактаулы исем бирелә. Дан эзләп ары - бире сугылмаса да, мактаулы исем аны “куып тотты”. Хәер, бу мәсьәләдә Миргарифан Мирзагалиевичның фикере башкачарак:

- Бер эш тә үзеннән - үзе эшләнми. Безнең районда мәдәниятнең торышы күп районнар көнләшерлек. Чөнки, бездә мәдәниятка игътибар зур. Район башлыгы без җырлаганга  кул чабып кына утырмый. Безнең мәдәният хезмәткәрләре һәрдаим аның ярдәмен тоеп эшли. Рәхмәт аңа!

Үзеңә рәхмәт, Миргарифан. Куйган хезмәтләрең, моңлы тавышың өчен. Алга таба да уңышлар юлдаш булсын үзеңә!,- дип яза Әхмәт Дусайлы, Миргарифан абый турында “Авыл утлары “ газетасында, “Алтын җирдә ятмый” дип исемләнгән мәкаләсендә.

**Ханнанова Венера Әмир кызы**



Күбәк авылында 1953 нче елның кышкы салкын бер көнендә, ягъни 3 нче декабрендә, Әмир абый белән Тәгъзимә апа  гаиләсендә, икенче бала булып, нәни кыз дөньяга аваз сала. Гаилә өчен бу күктән иңгән бәхет була. Шуларның барысын уйлаптыр, кызчыкка Венера дип исем кушалар 1961 - 1971 нче елларда Венера Әмир кызы Күбәк мәктәбендә белем ала. Шул дәвер балаларына хас булганча, октябрят, пионер, комсомол оешмаларында  тәрбияләнә. Комсомол оешмасында секретарь вазыйфаларын башкара.

Мәктәпне тәмамлагач, Венера Әмир кызын Үрәзмәт урта мәктәбенә математика укытырга билгелиләр. Үзе дә яңа гына парта арасыннан чыгуына карамастан, тәвәккәл кыз балаларга белем бирә башлый. Шул ук елны, читтән торып,Алабуга Дәүләт педагогия институтының физика - математика факультетына укырга керә.1973 - 1978 нче елларда Баек мәктәбендә, 1978 - 1980 нче елларда Тат Бүләр мәктәбендә математика укыта.

1977 нче елда Сәфәр егете Миргарифан Мирзагали улы белән тормыш

корып җибәрәләр. Икесе дә сәнгатькә гашыйк җаннар мәктәптә балаларга белем бирәләр. Миргарифан Мирзагали улын җитәкчелек югары белем алырга Саратов шәһәренә юллый. Венера Әмир кызы да тормыш иптәше белән бергә юлга чыга. Монда ул балалар бакчасына эшкә урнаша.

1985 нче елда Ханнановлар гаиләсе Салавыз - Мухан авылына күченеп кайта. Венера апага монда балалар бакчасы белән җитәкчелек эшен тапшыралар, ләкин мәктәп аны һәрвакыт үзенә тарта.

1986 елда Салавыз-Мухан мәктәбенә укытырга чакыралар. Шул елдан башлап, 2009 елга кадәр, Венера Әмировна математика фәненнән белем бирә. 1991 елдан - директор урынбасары, ә 1993 елдан укыту буенча директор урынбасары вазыйфасын башкара.

Венера Әмир кызы укучыларның гына түгел, һәрбер укытучының да остазы. Нинди генә сорау һәм киңәш белән мөрәҗәгать итсәң дә, төпле киңәшен бирә. Ул укытучылар һәм ата - аналарның хөрмәтен казанды, җитәкчелек тарафыннан да хезмәте югары бәяләнде. Район мәгариф бүлегенең Мактау кәгазьләре, “Мәгарифтәге казанышлары өчен” билгесе, РФ Фән һәм мәгариф министрлыгының Мактау грамотасы - болар барысы да укытучының тынгысыз хезмәт җимешләре.



**Тимергалиев Марс Мөдәссир улы**

1955 елның 23 июнендә Мөслим районы Иске Әлмәт авылында туа. Минзәлә педогогик училищесендә белем ала.

1976 елда, армия хезмәтен үтәп кайтканнан соң, Салавыз - Мухан мәктәбендә физкультура укытучысы булып эшли башлый. Физкультура һәм спорт буенча унышлары бик куп була.

Кайсы гына спорт төрен алса да, Марс Мөдәссир улы мәктәп командасын республика куләменә җиңүче итеп чыгармыйча туктамый.

1977 - 1987 нчы елларда ул хоккей командасын оештыра. Бу хоккей командасы районда гына тугел, республикада, шәһәр спорт командалары белән ярышып, призлы урыннар яулап кайта. Барысын да узләре эшли укучылар. Яланда боз шугалагы ясыйлар, коймасын тоталар, бозын катыралар, аны кардан чистартып торалар. Көн дә иртән йөгерәләр, укудан сон



тренировкалар үтә. Тырышлык юкка чыкмый. Марс абыйлары алардан чын спортсменнар ясый, көчле рухлы егетләр итеп тәрбияли.

1885 елда Тимергалиев М. М.  ВЛКСМ УК - ның Почет грамотасы һәм Чехословакиянең баш шәһәре Прагага хоккей буенча дөнья чемпионатына путевка  белән бүләкләнә.

Бу егетләр мәктәпне тәмамлап чыгып киткәч, мәктәптә кубрәк кызлар кала. 2001 - 2010 нчы елларда  Марс Мөдәссир улы  кызлар волейбол командасы оештыра. Волейбол командасы районда гына тугел, республика буенча призлы урыннар яулый. Шәһәр спорт мәктәбе командаларын җиңеп, зур уңышларга ирешеп кайта кызлар. 10 ел рәттән республика призерлары булалар. Аннан соң,  2010 нчы елдан башлап, районда үткәрелгән спартакиада уеннарында, 10 ел рәттән,абсолют беренче урынны алалар.




Тимергалиев Марс Мөдәссир улына 2010 елда “Татарстан республикасының Физик культура һәм спорт отличнигы” исеме бирелә..

Хәрби - спорт уеннары “Ажаган” буенча 1980 - 90 елларда бары тик беренче урынны гына алалар. “Жыр һәм строй”да тору һәм спорт ярышларында да катнашалар.



2015 елда мәктәп командасы “Жыр һәм строй” смотрында районда гран-при алдылар һәм Азнакай шәһәрендә ярышларда чыгыш ясадылар.

Салавыз - Мухан мәктәбе укучылары Марс Мөдәссир улы эшләгән чорда 21 тапкыр республиканың төрле ярышларына баралар. Районда бу кадәр республика ярышларында катнашкан бер мәктәп тә юк.

Класс җитәкчесе буларак та ул укучылар белән уртак телне тиз таба. Шуграк, тәртипсезрәк класс булса, аларны Марс Мөдәссировичка бирәләр. Кыска гына вакыт аралыгында ул менә дигән коллектив туплап, анда дустанә мөнәсәбәт булдырырып, ”шук - тәртипсез” укучылардан сәнгатьне - спортны сөючеләр, уку алдынгылары ясый да куя.



Марс Мөдәссир улы 2020 елда 65 яшенә район хакимиятенең мактау кәгазенә лаек булды.

Ул хәзер дә актив тормыш рәвеше алып бара. Районның “Сүнмәс дәрт” клубында алыштыргысыз гармунчы. Мәктәп тормышы белән кызыксынып, кирәк чакта төпле киңәшләре белән ярдәм итеп тора.

**Гайнетдинова(Мулллаянова) Фәридә Тимерҗан кызы** Мөслим районы Баек авылында 1958 нче елның 7 нче июнендә, 2 нче бала булып, дөньяга килә. Әти - әниләре колхозчылар, бик тырыш, хезмәт сөючән, гадел, ярдәмчел кешеләр була.



1965 нче елда укырга кереп, Баек урта мәктәбен 1975 нче елда яхшы билгеләренә генә тәмамлый. Математика, физика, химия фәннәрен бик яратып укый. Октябрят, пионер, комсомол сафларында тәрбияләнә, мәктәп активисты була.

Гаиләдә 4 бала, барысы да яхшы укып, тормышта үз юлларын таба. “Безне әти - әни хезмәт белән тәрбияләде, шуңа да хезмәт яратып үстек,” - дип искә ала Фәридә Тимерҗановна.

1975нче елда Алабуга Дәүләт педагогия институтына укырга керә, башлангыч класслар укытучысы белгечлеген сайлый. Институтны тәмамлагач, РОНО приказы буенча, Салавыз - Мухан сигезьеллык мәктәбенә рус теле һәм әдәбияты укытучысы итеп билгеләнә. Яшь белгечне мәктәп директоры Хәйдәров Миргазиян Хәйдәрович каршы ала. Берничә елдан башлангыч классны укытуга күчә. Ул вакытта интернатнын бер булмәсендә укыта, 3 әр классны берьюлы укытырга туры килә аңа.

“Миргазиян Хәйдәрович бик таләпчән директор иде. Ул чорда эшли алмыйча эштән китүче укытучылар да булды. Мәктәптә дәрес әзерләргә килү мәҗбүри булды, ял коннәрендә авылга кайтырга кушмый иде. Дәресләргә бик еш керә иде, укучы дөрес утырганмы, ручкасын дөрес куйганмы, һ.б.- дәрескә анализны шуннан башлый иде.

Мухан мәктәбендә директорлар алышынып торды, ләкин барысы белән дә дустанә мөнәсәбәттә эшләдек,”- дип искә ала Фәридә Тимерҗановна.

Укытучыларга агитатор булу да, ындыр табагында эшләүләр, чөгендер эшкәртүләр, төрле өмәләрдә, концерт - спектакльләрдә катнашу дисеңме, барысы да мәҗбүри, барысына да өлгерә Фәридә Тимерҗановна. Ә Шәрип сызасында, яшелчә бакчасында оештырылган пионер лагерьларында эшләү үзе кызык, үзе аеруча җаваплы эш була. 198 нче елда, коммунист булгач, политукулар үткәрү өчендә җаваплы була ул. “Политукулар үткәрү күңелемдә калган. Ул вакытта интернет юк, газета - журналларга чумып эзерләнә идем,”- дип искә ала ул.

Гаиләсендә дә уңган хуҗабикә, яхшы килен безнең Фәридә Тимерҗановна. 1985 нче елда авылның иң хезмәт сөюче кешесе Наил абыйга кияүгә чыга ул. Үрнәк гаилә булып, инде 35 елдан артык матур гомер кичерәләр.

Гомер сизелми дә үтә, бер урында 33 ел эшләп, 2014 нче елда лаеклы ялга чыга. 33 ел дәверендә күп төрле өстәмә эшләр дә алып бара әле ул.

Өлкән пионервожатый, пропагандист, профсоюз рәисе (21 ел), мәктәп яны участогында бакча мөдире, балалар белән эшләү инспекторы. Эшләгән чорында бер больничный алмыйча, бер дәрес калдырмыйча эшләве – үзе бер могҗиза!

Тырыш хезмәте югары бәяләнә: Фәридә Тимерҗановна бик күп рәхмәт хатлары, Почет грамоталары, "Мәгарифтәге казанышлары өчен" медале (кызганычка каршы, ни сәбәпледер, бүләк иясенә кайтып ирешми) белән бүләкләнә.

Гомер буе тик торуны белмәгән, тынгысыз Фәридә апабыз лаеклы ялда да бар эшкә дә өлгерә: бәйли, чигә, тегә, ашарга пешерегә ярата. Хәзер дә газета - журналлар укый: ил - көн, район - авыл, мәгариф яңалыклары белән танышып бара. Бергә эшләгән укытучылары ГалееваТ.М., Гараева Р.М., Биккинина Р.И., Мәрдәнова Б.Ә., Ханнанова В.Ә., Ханнанов М.М. Тимергалиев М.М. Гиздатова Э.М. , Хэйдәрова В. Н. белән аралашып яши.



**Биккинина Рәмилә Фаризовна** 1959 нче елның 3 нче сентябрендә Салавыз - Мухан авылында хезмәткәр гаиләсендә дөньяга килә. Метрәй сигезьеллык мәктәбендә белем ала. Мәктәптә укыганда ук ул оста оештыручы, сәнгатькә гашыйк була. Төрле концертлар, спектакльләрдә актив катнаша. Җәен каникул вакытларын ул бушка уздырмый: җәен, иртә торып, сыер савулар, ындыр табагында эшләүләр – болар барсы да аның хезмәт сөючәнлеген күрсәтә.

1976 нчы елда Мөслим урта мәктәбен тәмамлый. Укытучы булу хыялы кызны Алабуга дәүләт педагогия институтына алып килә. Ул физика - математика белгечлеген сайлый. Өченче курсны тәмамлагач, укуын читтән торып дәвам итә.

Хезмәт юлын 1980 нче елда Салавыз - Мухан сигезьеллык мәктәбендә башлап җибәрә. Шул дәвердән Рәмилә Фариз кызы физика һәм математика фәннәреннән балаларга белем бирә. Яшь белгеч буларак, аннан җәмәгать эшләрен дә "кызганмыйлар". Иртән мәктәптә белем бирсә, кичләрен төрле чараларда актив катнаша. 2 ел пионервожатый да була, шуның өстенә авылның радио тапшыруларын алып баручы, төрле чараларны оештыручы һәм алып баручы.



30 ел дәвамында класс җитәкчесе вазифасын алып бара. Укучылар белән оештырылган төрле кичәләр, ата-аналар, әбиләр белән очрашулар бик матур булып барсының да күңеленә кереп калды.”Ягез әле, этиләр”, “Спорт гаиләсе”, “Әниләр һәм бәбиләр” кичәләре, ”Уңыш бәйрәме”, Яңа ел бәйрәмнәре, Волгоград, Алабуга шәһәрләренә экскурсияләр – балаларның онытылмас хатирәләре. Табигатькә чыгу, чишмә операцияләрендә, агач утыртуда да актив катнаша ул укучылары белән.

Рәмилә Фаризовна физика - математика фәннәреннән 35 ел дәвамында балаларга белем бирә. Олимпиада призерлары әзерләү, уку елына 2 шәр классны имтиханга әзерләү – укытучының тынгысыз хезмәт җимешләре. Математика фәненнән район, республика, халыкара математик конкурсларына әзерләнеп, укучылары бу конкурсларда призлы урыннар яулыйлар.



Хезмәт юлының соңгы сигез елында ул тәрбия эшләре буенча директор урынбасары вазифасын да башкарды. Дәресләрдән соң үткәрелгән төрле чаралар укытучының иҗади якын килеп эшләвен күрсәтә. Район завучларына күрсәтелгән “Сугыш йоткан балачак” кичәсе, район күләмендә уткәрелгән “Уйнагыз, гармуннар”, авыл халкы өчен дә курсәтелгән “Яңа ел” кичәләре – боларның ачык мисалы. Төрле бәйгеләрдә алган урыннар, мәктәптә генә түгел, авыл, район күләмендә уздырылган чаралар Рәмилә Фаризовнаның оста оештыручы икәнен күрсәтә. Күп еллар дәвамында ул балаларга үзендәге матур сөйләм, сәхнә осталыгын бирә. Укучылары Яр Чаллы шәһәрендә үткәрелгән “Сәхнә көзгесе” конкурсында 2 тапкыр 2 нче урын яулыйлар.

Авылыбыз сәхнәсенең алыштыргысыз сүз остасы, һәртөрле мәдәният чараларын алып баручы да ул. Мухан авылы театрының алыштыргысыз актрисасы драматик рольләрдә уйнарга ярата. “Зәңгәр шәлдә” Заһира , “Әни килде”дә әни рольләрен бик оста яктырта. 20 елга якын авыл Сабантуен алып баручы булды. Мәктәптә оештырылган туган якны өйрәнү музеенда “Авыл тарихы” бүлеген тирәнтен өйрәнеп, альбом төзүдә дә аның өлеше зур.

Укытучының куйган хезмәтләре югары бәяләнде: РТ мәгариф бүлеге грамотасы, район мәгариф бүлегеннән бирелгән күпсанлы грамота һәм

рәхмәт хатлары - барысы да шуның ачык мисалы.

Сабырлыкны, тыйнаклыкны ходай кызганмый биргән аңа. 28 ел бианасы белән дус тату гомер кичереп, аны хөрмәтләп, карап соңгы юлга озата. Тормыш иптәше Миңнулла абый белән 3 балага гомер биреп, бүген 6 оныгына куанып яшиләр. Уңган хуҗабикә, күршеләре һәм туганнары өчен дә ул - ныклы таяныч.

Рәмилә Фаризовна - исемен Мухан мәктәбе тарихына зур хәрефләр белән язып куярга лаеклы шәхес.



**Латыйпова Галия Хафазетдин кызы**

1992 нче елның 10 нчы августыннан Салавыз – Мухан мәктәбенә башлангыч сыйныфлар укытучысы итеп күчерелә. Аңа кадәр, ягъни 1985 нче елдан, Ташлыяр урта мәктәбендә югары сыйныфларда татар теле һәм әдәбиятыннан белем бирә.

1997 – 2018 еллар аралыгында югары сыйныфларда татар теле һәм әдәбияты дәресләрен укыта. Укыту дәверендә сыйныф җитәкчесе, дәрестән тыш эшләрне оештыручы педагог һ.б. вазыйфаларны үти.

Салавыз – Мухан мәктәбе һәрвакыт барлык өлкәдә дә алдынгылар рәтендә булды. Укучылар, укытучылар бик актив эшчәнлек алып бардылар .

Олимпиадаларда гел призлы урыннар яуладылар. Татар теле һәм әдәбияты буенча республикакүләм фән олимпиадасында 2009 нчы елдан призерлар әзерләде. Шушы хезмәтләре өчен Галия Хафазетдин кызына 2005 нче елда Татарстан Республикасының Мактау Грамотасы, 2010 нчы елда Россия Фелерациясенең Мактау Грамотасы бирелде.

2011нче елда “Ел укытучысы” бәйгесендә катнашып, районкүләмендә беренче урынны яулады. 2012 нче елда “Наш лучший учитель” бәйгесендә грантка ия булды.

**Мәктәп елларыннан истәлекләр һәм фотолар.**



Мәктәптә чараларның  бик күп төрләре оештырылды. Укучылар өчен ел саен сабантуй үткәрелде, монда төрле уеннар, ярышлар,  бәйгеләр була иде. Укучылар монда бик теләп катнаша иделәр.

Безнең бакча районкүләмендә иң - иң яхшылардан булды. Укучылар үз хезмәтләрен кертәләр һәм кыш буе салат, кайнатмалар белән сыйландылар.



2004 нче елда  Гарифуллина Ләйсән белән “Ялкын” журналының 80 еллыгында Пирамида күңел ачу үзәгендә катнаштык. Ул үзәкнең ачылган чоры иде. Өч көн дәвам иткән бу чарага районнан ике бала: берсе безнең мәктәптән Ләйсән, икенчесе Мөслим урта мәктәбе укучысы иде. Ләйсән шигырьләр иҗат итеп, журналга  җибәргән идек. Шуннан чакыру алдык, ял итеп, Казан  шәһәре  буйлап экскурсиядә булып кайттык.



Укытучылар белән дә байтак шәһәрләрдә булдык.  Түбәндәге фотода без Милли музейда .



Яңа ел кичәләре икешәр этапта үтә иде. Көндез башлангыч һәм җиденчеләр өчен үткәрелсә, кичке якта югары сыйныфлар өчен оештыра идек. Монда барлык балалар да үз осталыкларын күрсәттеләр.

